Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы
Олы Әтнә авыл җирлеге Советы Карары

« 11» сентябрь 2020 ел № 154

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы «Олы Әтнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль хезмәткәрләре саны факттагы аларны акчалата тоту чыгымнары турында квартал саен халыкка игълан итү тәртибен раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль (соңгы үзгәрешләр белән) законның 52 статьясындагы 6 өлеше , Россия Федерациясе Бюджет кодексының 36 статьясы , Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының "Олы Әтнә авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының«Олы Әтнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль хезмәткәрләре саны факттагы аларны акчалата тоту чыгымнары турында квартал саен халыкка игълан итү тәртибен кушымта нигезендә расларга.

2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында, Әтнә муниципаль районының Интернет челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб–адресы буенча урнаштырылганнан соң үз көченә керә.
4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җавапчылыгымда калдырам.

Әтнә муниципаль районы
Олы Әтнә авыл жирлеге башлыгы Г.Г.Хакимов

Совет Большеатнинского сельского поселения
Олы Әтнә авыл җирлеге Советы
ИНН 1610000571

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы
Олы Әтнә авыл җирлеге Советының 2020 елның
«11»сентябрендәге 154 номерлы карарына
1 нче номерлы кушымта

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы «Олы Әтнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль хезмәткәрләре саны факттагы аларны акчалата тоту чыгымнары турында квартал саен халыкка игълан итү тәртибе**

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының «Олы Әтнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең муниципаль хезмәткәрләре саны һәм аларны акчалата тоту өчен факттагы чыгымнар турында квартал саен мәгълүматларның (алга таба - тәртип) халыкка җиткерүнең әлеге тәртибе Россия Федерациясе Бюджет кодексының 36 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 52 статьясындагы 6 өлеше нигезендә гамәлдәге редакциядә эшләнде һәм югарыда күрсәтелгән кварталлык белешмәләрне бирү, раслау һәм рәсми бастырып чыгару процедурасын билгели.
2. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының «Олы Әтнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең муниципаль хезмәткәрләре саны һәм аларны тотуга факттагы чыгымнар турында мәгълүмат күрсәтелгән органнарның вәкаләтле затлары тарафыннан квартал саен, хисап чорыннан соң килүче айның 15 числосына кадәр Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының «Олы Әтнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенә бирелә.
3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының «Олы Әтнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең вәкаләтле затлары бирелә торган мәгълүматның үз вакытында, дөреслеге, аның Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының «Олы Әтнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджеты үтәлеше турындагы хисаплылыкка, башка рәсми хисаплылыкка туры килүе өчен шәхси җаваплылык тоталар.
4. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының «Олы Әтнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җаваплы бүлекчәсе тарафыннан бирелгән мәгълүмат нигезендә хисап чорыннан соң килүче айның 20 числосына кадәр Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының «Олы Әтнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең саны һәм аларның акчалата тоту өчен факттагы чыгымнары турында квартал саен әлеге Тәртипкә кушымта нигезендә әзерләнә.
5. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының «Олы Әтнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең муниципаль хезмәткәрләре саны һәм аларны тоту өчен факттагы чыгымнар турында квартал саен Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының «Олы Әтнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең хисап чорыннан соң килүче айның 20 числосыннан да соңга калмыйча хәбәр ителергә тиеш.

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы «Олы Әтнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль хезмәткәрләре саны факттагы аларны акчалата тоту чыгымнары турында квартал саен халыкка игълан итү тәртибенэ кушымта**

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының " Олы Әтнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләре саны һәм аларның 20__ нчы елнын____квартал өчен акчалата тотуга факттагы чыгымнары турында МӘГЪЛҮМАТ**

(ел башыннан бирле үсеп килүче нәтиҗә белән)

» муниципаль берәмлеге

| Хезмәткәрләрнең категориясе | исемлек буенча уртача сан эшче саны | хисап чорында хезмәткәрләрнең эш хакына факттагы чыгымнары-мең сум |
|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы «Олы Әтнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге муниципаль хезмәткәрләре | | |